**Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Кайбыч авыл җирлегенең Кайбыч авылында гражданнар җыены карары**

21 март 2024 ел № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Кайбыч авыл җирлегенең Кайбыч авылында гражданнар җыены

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Кайбыч авыл җирлегенең Кайбыч авылы гражданнары җыенының 2023 елның 1 ноябрендәге 1нче номерлы карарының 2 пунктына үзгәрешләр кертергә һәм аны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:.

“2. Җыелган акчаны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

-торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;

-урам яктыртуын җиһазлау.”

2. Җыен нәтиҗәләрен Кайбыч авыл җирлегенең Кайбыч авылында махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Кайбыч авыл җирлеге башлыгы __________ С.И.Нуретдинова

Халык җыены секретаре __________ А.Т.Шиһабиева